ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.04.2020 г. М ө с л и м № 209

**Мөслим муниципаль районы гражданнарына аерым социаль ярдәм чараларын күрсәтү срогын озайту турында**

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы һәм «Аерым социаль ярдәм чараларын күрсәтү срогын озайту турында» 2020 елның 1 апрелендәге 241 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын тормышка ашыру максатларында, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 24 сентябрендәге 574 номерлы Башкарма комитет карары нигезендә, җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган, дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алучы Мөслим муниципаль районы гражданнары гаиләләренә, 2020 елның 30 сентябренә кадәр гамәлдән чыга торган социаль ярдәм күрсәтү чаралары бирүне, кабат гариза тапшырмыйча, 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Әхмәтов И.Х.**